Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы
КАРАРЫ

Азнакай шәһәре №321-42 «05» февраль 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2012 елның 28 маендагы 154-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (29.01.2014 №289-40, 12.08.2014 №316-45, 30.04.2015 №361-52, 07.12.2015 №17-3, 18.08.2016 №60-9, 22.03.2017 №104-17, 27.12.2017 №166-24, 22.08.2018 №200-30, 20.08.2019 №275-35, 24.08.2020 №362-48, 26.10.2021 №85-11, 12.10.2022 №166-19, 18.04.2023 №212-24, 28.05.2024 №281-34 карарлар редакциясендә)», түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :

**1.1. 1 статьяда « Муниципаль район һәм аның статусы»:**

беренче пунктта "Азнакай муниципаль районы" сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы " сүзләрен өстәргә»;

икенче пунктта «Азнакай муниципаль районы» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы»сүзләрен өстәргә.

**1.2. «2 статья. Районның территориаль төзелеше»**

икенче пунктта «Азнакай муниципаль районы» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы»сүзләрен өстәргә.

**1.3. "9 статья. Районның муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы** " үз көчен югалткан дип танырга.

**1.4. «27 статья. Район Советы депутаты статусы»:**

6.3 пунктының а) пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының " сүзләрен төшереп калдырырга»;

6.3 пунктының б) пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының " сүзләрен төшереп калдырырга»;

**1.5. "39 статья. Район Башлыгы Статусы»:**

2 пунктның а) пунктчаксында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга»;

2 пунктның б) пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга»;

**1.6. "42 статья. Муниципаль берәмлек Башлыгын отставкага җибәрү»**

түбәндәге эчтәлекле 6) пункт өстәргә:

«6. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләргә системалы рәвештә ирешмәү.».

**1.7. "43 статья. Район Башлыгы Урынбасары»:**

7 пунктның а) пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга»;

7 пунктның б) пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга»;

1.8. **«46 статьяда. Башкарма комитет вәкаләтләре»:**

түбәндәге эчтәлекле 1 пунктның 3 пунктчасындагы ундүртенче абзацны өстәргә:

« - муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне оештыру».

**1.9. "78 статья. Районның муниципаль мөлкәте»:**

1 пунктның 5) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре, 16 статьясындагы 3 өлеше һәм 16.2 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

1.10. **79 статья «Районның муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү»**

түбәндәге эчтәлекле дүртенче, бишенче пунктлар өстәргә:

«4. Муниципаль берәмлекләр муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципальара оешмалар төзүдә катнаша ала. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

Гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең максатларын, шартларын һәм эшчәнлек тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, үз вазыйфасына билгеләп куя һәм әлеге предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең җитәкчеләрен вазыйфасыннан азат итә, аларның эшчәнлеге турында муниципаль берәмлек уставында каралган тәртиптә хисапларны тыңлый.

Җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль казна учреждениеләре йөкләмәләре буенча субсидияләп җавап бирәләр һәм аларны федераль законда билгеләнгән тәртиптә үтәүне тәэмин итәләр.

5. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасының яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасының электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

**1.11. «81 статья. Муниципальара предприятиеләр учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләрен» яңа редакциядә бәян итәргә:**

**"81 статья. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен муниципаль берәмлекләрнең финанс чараларын, матди һәм башка ресурсларын берләштерү максатларында оештырыла.

2. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары карары буенча гавами булмаган акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә оештырыла.

3. Муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре үз эшчәнлекләрен Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, башка федераль законнар нигезендә гамәлгә ашыралар.

4. Муниципаль хуҗалык җәмгыятьләрен дәүләт теркәвенә алу "Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында" 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Җирле үзидарә органнары муниципальара матбугат чарасын һәм “Интернет” челтәре басмасын гамәлгә куюда ярдәм күрсәтә алалар.”

**1.12. Муниципальара хезмәттәшлек рәвешләре» 81.1 статьяны өстәргә:**

**"81.1 статья. Муниципальара хезмәттәшлек рәвешләре**

1. Муниципальара хезмәттәшлек түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә әгъзалыгы;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын оештыру;

3) муниципаль берәмлекләр тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү;

5) Россия Федерациясе субъектлары муниципаль берәмлекләре советларының үзара хезмәттәшлеген оештыру.

2. Муниципаль берәмлекләр берләшмәләренә, муниципальара хуҗалык җәмгыятьләренә, муниципаль берәмлекләр тарафыннан гамәлгә куелган коммерциягә карамаган оешмаларга районның җирле үзидарә органнары вәкаләтләре бирелә алмый.».

2. Дәүләт теркәвеннән соң, әлеге карарны рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, түбәндәге веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakayevo.tatar.ru, шулай ук Россия Федерациясе Юстиция Министрлыгы порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар»(http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф, челтәр басмасы сыйфатында теркәлү: Эл №ФС77-72471 2018 елның 05 мартыннан) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин